Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XI-1**

Балык Бистәсе штп. 2021 елның 31 августы

Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасы турында

Крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән гамәлгә ашыру өчен милек итеп бирелә торган җир кишәрлекләренең иң чик минималь күләмен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Җир кодексының 34 маддәсендәге 1 пунктына һәм Татарстан Республикасы Җир кодексының 40 маддәсендәге 2 пунктына ярашлы рәвештә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән төзелә торган яңа җир кишәрлегенең минималь күләме нигезендә, Балык Бистәсе районының авыл хуҗалыгы предприятиеләре чикләрендә авыл хуҗалыгы җирләрен Россия Федерациясе Президентының “Гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыру нормасын билгеләү тәртибе турында” 1992 елның 2 мартындагы 213 номерлы Указы һәм җир реформасы һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына ярдәм итү буенча РСФСР Дәүләт комитетының 1992 елның 10 гыйнварындагы 3-5/51 номерлы хатына таянып гражданнарның милкенә бушлай тапшыру йомгаклары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Авыл хуҗалыгы җирләрен хосусыйлаштыру вакытына билгеләнгән гражданнар милкенә җир кишәрлекләрен бушлай тапшыруның уртача район нормасын 5,17 гектар күләмендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.
3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов